Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам нуры

№ 7 (635) 14 апрель, 2017 ел (1438, Рәҗәб) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

# Мөселман яшьләре көрәштә чыныга

9 апрельдә Чаллының “Витязь” спорт комплексында мөселман яшьләренең Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте кубогына татарча көрәш һәм кул көрәше буенча IX Берләштерелгән турниры узды. Ул быел җөмһүриятебезнең 19 районыннан (Алабуга, Азнакай, Актаныш, Әлмәт, Нурлат, Аксубай, Балтач, Баулы, Буа, Биектау, Балык Бистәсе, Түбән Кама, Тукай, Минзәлә, Яңа Чишмә, Зәй, Саба, Чистай, Чаллы), Башкортостаннан (Уфа, Октябрьский шәһәрләре, Балтач, Борай, Зианчура районнары), Киров, Оренбург өлкәләреннән 103 көрәшчене үзенә тартты. Алар башта намаз гыйбадәтен ни дәрәҗәдә белүләре буенча әңгәмә уздылар. Көч сынашырга теләүчеләр арасында татарча көрәш, билбау, кул көрәше буенча 10 спорт мастеры, 7 мастерлыкка кандидат бар иде. Калган катнашучыларның да күбесе төрле разрядларга ия иде. Шунсы игътибарга лаек: турнирда ел саен катнашучылар да байтак. Ә инде олыгая төшкәннәр ярышка уларын җәлеп итәләр. Мәсәлән, Чаллыдан авыр категориядә берничә мәртәбә җиңүче спорт мастеры Дамир Хәйриев быел татарча көрәшкә улы Данилне алып килде.

Турнирны ачу тантанасында көрәшчеләрне Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Хәлимов, татарча көрәш ветераны Фрил Әхмәтов котладылар һәм җиңү теләделәр. Камил хәзрәт пәйгамбәретбезнең (с.г.в.) спортны бик яратуын әйтте, мөселман яшьләренә аның үрнәгенә иярү кирәклеген искәртте. Ул чыгышында пәйгамбәребезнең (с.г.в.) Рукана белән көрәшүе һәм аны җиңүе, берничә сарык отуы хакындагы хәдисне дә искә төшерде. Тантаналы өлеш Мөфти хәзрәтнең Коръән укуыннан һәм дога кылудан башланды.

Кискен көрәш 6 сәгать буена барды. Көрәшчеләр фәкать өйлә намазына гына туктадылар. Һәм менә беренче җиңүчеләр билгеле булды. Кул көрәшендә 70 кг. кадәр үлчәүдә иң көчлесе булып Түбән Кама районы вәкиле Илгиз Нәфыйков танылды. Ул шулай ук җирәбә буенча турнирның иң олы бүләген — Олуг хаҗга Юлламаны отты. Бу авырлыкта II, III урыннарны Чаллыдан бертуган Руслан һәм Рим Хәмидуллиннар яулады. Кул көрәшендә 85 кг. кадәр авырлыкта Чаллыдан спорт мастеры Руслан Касыймов; II урында — Аксубайдан Рөстәм Бикмөхәммәтов; III урында — Буадан татарча көрәш буенча спорт мастерлыгына кандидат Марат Миначев. 100 кг нан артык авырлыкта җиңүчеләр: I урында - Әлмәттән спорт мастеры Фәнил Мингазов; II урында — Балтач районы командасыннан спорт мастеры Фәрхәт Фәйзуллин; III урында Башкортостанның Зианчура районы вәкиле Наил Хәмидуллин.



Җиңүчеләргә дипломнар һәм акчалата призлар тапшырылды. Батырларга “Чаллы-Икмәге” җәмгыяте күчтәнәче — чәкчәкләр, “Автомәктәп”тә ташламалы уку өчен сертификатлар тапшырылды. Шулай ук турнирның татарча көрәш һәм кул көрәше буенча баш батырлары билгеләнде. Мондый исемгә татарча көрәш буенча Фәрхәд Фәйзуллин лаек булды. Аңа тәкә бүләк ителде. Ә кул көрәшендә барлык көндәшләрен дә бик җиңел генә җиңгән спорт мастеры Илдар Сәхипов баш батыр булып калды. Аннары һәр авырлык категориясе батырлары бергә җыелдылар һәм алар арасында җирәбә уйнатылды. Алда әйтелгәнчә, Олуг хаҗга









Мөхәммәд Нуцалханов I, Башкортостанның Балтач районы вәкиле Радим Нургалиев II, Чаллыдан Фәрит Кубиев III призларга ия булды. 85 кг. артык авырлыкта Башкортостанның Балтач районы вәкиле, бу авырлыкта үткән елгы чемпион Илдар Сәхипов җиңде. Ә II, III урыннарны Чаллыдан Фәнис Нурхәмитов һәм Чистайдан Альберт Шәрифуллин бүлештеләр.

Татарча көрәш буенча 60 кг кадәр авырлыкта иң яхшы нәтиҗәне Актаныштан 18 яшьлек Раббани Нургалиев күрсәтте. II урында Әлмәттән спорт мастеры Рузил Ганиев, III — Азнакайдан I разрядлы 18 яшьлек көрәшче Артур Солтанов. 70 яшькә кадәрге авырлыкта җиңүчеләр: I һәм III призлы урыннарны Алабугадан бертуган Ислам һәм Булат Фәләхovлар яулады. II урында — Чирмешәннән Марат Кәримов. 80 кг. кадәр авырлыкта Минзәләдән Данис Гәрәев беренче призны яулады. II урында - Баулыдан бил бау көрәше буенча спорт мастерлыгына кандидат Илмир Сабиров, III урында — Оренбург өлкәсе Богырыслан шәһәреннән 20 яшьлек Айрат Сәмигуллин. 90 кг. кадәр авырлыкта Әлмәттән спорт мастеры Илнар Кәримов батыр калды. II урында - Зәйдән бил бавы буенча спорт мастеры Руслан Хәмидуллин, III урында — Чаллыдан Илнур Кариев. 100 кг. кадәр авырлыкта җиңүчеләр: I урында Балтачтан татарча көрәш буенча бару бәхете Түбән Кама районы вәкиле Илгиз Нәфыйковка елмайды. Ә командалар арасында турнир хаҗәлары җиңүче дип табылды. Чаллы командасына нәзарәт кубогы тапшырылды. Икенче урында Әлмәт, өченчедә Балтач районы командалары.

Турнир Диния нәзарәте, Чаллы шәһәре Башкарма комитеты, Чаллы Мөхтәсибәте, нәзарәтнең Хәләл стандарты комитеты һәм Чаллы шәһәренең мөселман эшмәкәрләре ярдәме белән үткәрелде.

**Рәсемнәрдә:** Мөфти Камил хәзрәт Илгиз Нәфыйковка турнирның иң олы бүләген тапшыра; турнирдан күренешләр; җиңүче Чаллы командасы; 60 кг. кадәрге авырлыкта җиңүчеләрне Җәлил хәзрәт бүләкли.



# Аллаһны бөекләү

Ий Аллаһка иман китергән бәндәләр! Аллаһтан куркыгыз хакыйкый курку белән. Аллаһка тәкъва булыгыз!

Кадерле дин кардәшләрем! Һәрберебезгә вәҗип булып тора, Аллаһны хакыйкый бөекләү белән бөекләү. Әйе, нишләп соң безгә Аллаһны хакыйкый бөекләү белән зурламаска? Ул бит бөтен галәмнәрнең Раббысы. Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә Аны хакыйкый бөекләү белән зурламаучыларны ачуланып әйтә:

**“Алар Аллаһны чын итеп зурламадылар, ә бит кыямәт көнендә җирнең һәм күкнең һәр каты Аллаһның учында булыр, Аллаһ мөшрикләр сыйфатлаган тиешсез сыйфатлардан күпкә бөеграк.”**

Аллаһ Тәгалә ар-Рахман сүрәсендә, кешеләргә бу дөньяда һәм ахирәттә биреләчәк киң нигъмәтләрен һәм сый-хөрмәтләрен атаганнан соң әйтә:

**“Дөреслектә Раббыңның исеме мөбәрәк һәм Ул: Зулҗәләл ягъни бөек, газым һәм хөрмәт иясе.”**

Коръәннең күп аятьләрендә һәм сөннәтнең күп хәдисләрендә, Аллаһ Тәгалә безне Аны хакыйкый зурлау белән бөекләргә һәм Аңа гына гыйбадәт итәргә әмер итә. Шуңа күрә кем Аллаһның бөеклеген һәм чиксез кодрәтен аңласы килсә, Аллаһны хакыйкый бөекләүгә ярдәм итүче ике юлны сайласын:

Беренче юл: Аллаһ сүзләренең, ягъни Коръән аятьләрнең тирән мәгънәләренә төшенү.

Икенче юл: Аллаһның аятьләре турында уйлану, ягъни чиксез диңгезләр, биек таулар, кояшның чыгуы һәм батуы, табигатьнең үзгәрешләре, кешенең үлүе һәм барлыкка килүе, галәмдә тәртип булу һәм Аллаһның, безнең тирә-ягыбызда булган башка аятьләре турында фикерләү.

Беренче юл турында Аллаһ Тәгалә әйтә:

**«Нишләп соң алар Коръән аятьләренең мәгънәләре турында фикерләмиләр, әгәр фикерләп карасалар иман китерерләр иде, әллә аларның калепләре ачылмаслык йозак белән бикләнгәнме?”**

Шулай ук Аллаһ Тәгалә икенче аятьтә әйтә:

**“Без сиңа, Ий Мөхәммәд, мөбәрәк Коръән аятьләрен алар турында фикерләү һәм вәгазьләнү өчен иңдердек.”**

Коръән аятьләре безне Аллаһ белән, Аның хокуклары белән таныштыра, ничек дөрес итеп Аңа гыйбадәт кылырга өйрәтә.

Аллаһны хакыйкый бөекләүгә ярдәм итүче икенче юл турында Аллаһ Тәгалә әйтә:

**“Нишләп соң алар җир һәм күкләрнең төзелешенә игътибар итмиләр?** Әгәр дә алар аның турында фикерләсәләр, әлбәттә, аларны Аллаһ кына юктан бар иткәнлеген танырлар иде.”

Шулай ук сөекле пәйгамбәребез дә безне Аллаһның мәхлукләре турында фикерләргә чакыра:

*“Аллаһның мәхлукләре турында фикерләгез, Аллаһ турында фикер йөртмәгез.”*

Шуңа күрә әгәр дә син, Аллаһның бөеклеген аңлыйсың килсә, Аның мәхлукләренә игътибар ит, Аллаһ Тәгалә әйтә:

**“Җир һәм күкләрнең төзелеше, төн белән көннең бер-берсе белән алышынуы, кешеләргә кирәк нәрсәләрне күтәреп диңгезләрдә көймәләрне йөртү, күктән яңгыр яудырып үлгән җирне тергезү, җир йөзендә төрле хайваннарны юктан бар итү, җилне һәм болытларны йөртү - әлбәттә болар барсы да Аллаһның барлыгын һәм берлеген исбатлый торган аятьләр.”**

Шулай итеп безгә хезмәт итүче тирә-ягыбызда булган Аллаһның аятьләре Аллаһның бөеклеген исбатлый, чөнки Аллаһтан башка беркем дә шушы бөек галәмне безгә буйсындыра алмас иде. Шуңа күрә иман китергән бәндә, ни хәтле күбрәк шушы аятьләргә караса, алар турында фикерләсә, шул чама хәтле аның Раббысын бөекләве һәм белеме артачак һәм ул тизрәк Аллаһны зикер итәргә ашыгыр, Аңа шөкер булыр, гыйбадәте дә яхшы якка үзгәрер.

Шулай ук мөэминнәр Коръән аятьләрен укып Үзләренең Раббылары турында бик күп файдалы гыйлемнәр туплый алалар. Дөреслектә, шушы Коръән аятьләре калебнең һәм рухның ризыгы, акылның нуры, кешеләргә туры юлны күрсәтүче маяклар!

Мөэминнең яшәү-эше яхшы якка үзгәрмәс, хәере һәм бәрәкәте камил, бәхете тәмам, иминлеге тулы булмас, иллә мәгәр шушы Коръән аятьләрен укып, аларның бөек мәгънәләрен фикерләгәнчегә чаклы. Чөнки шушы аятьләрдә һидаять, нур, рухи ризык, шифа, чын яшәү һәм Аллаһның безгә чиксез рәхмәте!

Кем дә кем шушы күрә һәм укый торган аятьләргә игътибар итмәсә, алар турында фикерләмәсә, шул чын мәхрум — өлешсез, буш калучы булыр, үзүзенә наданлык сәбәпле зарар китерер. Кызганычка каршы, шушы мәсьәләдә мөселманнар арасында мәхрум булучылар күп, алар Аллаһның аятьләрен күрмиләр! Һәм шушы сәбәпле аларның гыйбадәтләре бик зәгыйфь, алар Аллаһның бөеклеген аңламыйлар. Шуңа күрә гөнаһка җиңел карыйлар, Аллаһка хакыйкый буйсыну белән буйсынмыйлар, Аллаһның чиксез нигъмәтләренә көферлек кылалар, шөкер итмиләр, Аллаһны баскан килеш тә, утырган килеш тә, яткан килеш тә зикер итмиләр, аларның Аллаһ белән элемтәсе бик зәгыйфь һәм кечкенә.

Кадерле мөселман кардәшем! Нишләп соң син хакыйкый гыйбадәт белән Аллаһны бөекләмисең? Нишләп соң син Аллаһ хакын үзеңнең хакыңнан алда куймыйсың? Нишләп соң син кешеләрнең ризалыгына ирешәм дип, Аллаһның ачуын китерәсең? Син белмисеңме, Аллаһ бит сиңа әти-әниеңнән дә рәхимлерәк. Ул сине юктан бар итте! Ул сине ризыкландыра! Ул сине бәлаләрдән саклый! Ул сиңа Үз ярдәмен бирә! Кая соң синең Коръәнгә, чын мәхәббәткә, тәвәкәлеккә нигезләнгән гыйбадәтең?

Дөреслектә, Аллаһ Тәгалә чиксез хикмәт иясе. Һәм кешеләргә төрле сынауларны бирү - Аллаһның хикмәтеннән. Аллаһ Тәгалә һәрберебезне нигъмәтләрне бирү һәм аларны тартып алу, дәрәҗәбезне күтәрү һәм түбәнчелеккә төшерү, сәламәтлекне һәм чирләрне бирү, куәт һәм зәгыйфьлек белән безне барыбызны да сыный. Болар бөтенесе дә безнең хакыйкый гыйбадәтебез һәрберебезгә ачылсын өчен эшләнә. Ул гыйбадәт Аллаһкамы? Әллә икенче затларга булырмы? Шуңа күрә әгәр дә берәр нинди сынаулар килсә, Аллаһ турында начар уйлар уйлый күрмә. Чөнки Аллаһ Тәгалә Хакимун, Галим, Хикмәт иясе, Бар нәрсәне белүче! Шуңа күрә гыйлем әһелләре әйттеләр:

*“Сиңа берәр нинди чир бирелсә, ул синең сәламәтлегең өчен генә! Сиңа бирелгән фәкыйрьлек, син берәр көнне бай булыр өчен. Сиңа бирелгән курку һәм иминсезлек, киләчәктә тормышың имин булуы өчен.* Һәм үлү синең кыямәт көнендә мәңге яшәвең өчен генә! Шуңа күрә, кадерле мөселман кардәшем, Аллаһка буйсын һәм Аның хикмәтенә каршы чыга күрмә. Чөнки Аллаһ Тәгалә Ул:

**“Ул соралмас, ә сез үзегезнең кылган гаммәлләрегез өчен соралачаксыз.”**

Кадерле мөселман кардәшем, вәҗип булып тора сиңа Аллаһка хакыйкый гыйбадәт белән якынаерга. Ягъни әгәр дә Аллаһ берәр нәрсә әмер итсә, шунда ук буйсынырга. Әгәр дә Аллаһ сине берәр нәрсәдән тыйса, шунда ук шушы әйберләрне калдырырга. Әгәр дә Аллаһ сине чакырса, шунда ук җавап бирергә. Әгәр дә Аллаһ сиңа берәр нәрсә турында хәбәр бирсә, аңа ышанырга. Әгәр дә сине берәр нәрсә белән кызыксындырса, тизрәк шушы әйбергә ашкынырга. Әгәр дә Аллаһ Тәгалә сине берәр нәрсә белән куркытса, шушы әйбердән читләшергә. Әгәр дә шулай эшләсәң, синең турында: “Бу кеше Аллаһны хакыйкый бөекләү белән зурлый,”- дип әйтергә була.

Кадерле дин кардәшем, Аллаһ белән элемтәне ныгыт, үзеңнең динеңне өйрән. Шулай эшләсәң, Аллаһ белән хакыйкый танышырсың.

Кадерле мөселман кардәшем, бел: син Аллаһка мохтаҗ!

Ә Аллаһ Тәгалә: **“Дөреслектә Аллаһ Бай**, бер нәрсәгә дә мохтаҗ түгел!” (Локман сүрәсе, 26).

Кадерле мөселман кардәшем, бел: син зәгыйфь!

Ә Аллаһ Тәгалә: **“Бар нәрсәгә кодрәтле һәм бар нәрсәне җиңүче!”** (Шура сүрәсе, 19).

Кадерле мөселман кардәшем, бел: син җаһил һәм надан!

Ә Аллаһ Тәгалә: **“Бар нәрсәне белүче!”** (Хадид сүрәсе, 3).

Кадерле мөселман кардәшем, бел: син гөнаһлы!

Ә Аллаһ Тәгалә: **“Гафу итүче, рәхимле!”** (Юныс, 107).

Аллаһ бар нәрсәне белүче, шуңа күрә Ул сиңа, сине яхшы якка үзгәртә торган сынауларны гына бирә. Аллаһ Тәгалә Хаким. Шуңа күрә ул сиңа файдалы нәрсәләрне генә тәкъдир итә. Аллаһ Тәгалә рәхимле. Шуңа күрә Ул синең хаталарны гафу итә.

Без намазның һәр рәкәгатендә укыйбыз: **“Сиңа гына гыйбадәт кылабыз, Синнән генә ярдәм сорыйбыз.”**

Кадерле дин кардәшем, Аллаһка гыйбадәт кылуны бер мизгелгә дә калдырудан сак бул. Тормышның нинди генә хәлләре булмасын - фәкыйрьлектә яисә бай булган чакта, сөенечтә яисә көенечтә, сәфәрдә яисә өйдә, яшь чакта яисә картлыкта, куәтле яисә зәгыйфь булган чакта, минем гыйбадәт кылырга көчем җитмәс дигән фикер сәбәпле, Аллаһка гыйбадәт кылуны калдыра күрмик. Әгәр дә Аллаһ Тәгалә берәр нәрсәне әмер иткән булса, буйсынырга тизрәк ашыгыйк. Әгәр дә берәр нәрсәдән тыйса, шушы әйберләрне калдырырга ашыгыйк. Чөнки: “Сиңа гына гыйбадәт итәбез дигән сүзебез, ул: “Син әмер иткән әйберләрне кылабыз, Син тыйган нәрсәләрдән тыелабыз” дигән мәгънәне аңлата. Әгәр дә шулай эшләсәк Аллаһ Тәгалә шушы гыйбадәтне кылырлык Үзенең ярдәмен вәгъдә итә. Шуңа күрә кыямәт көнендә Аллаһ каршында баскан чакта гозерең нинди булыр, әгәр дә син Аллаһка каршы чыгып икенче затларга буйсындың, Аллаһка каршы чыгып икенче затларны сөендердең, Аллаһның шәригатеннән үзгәрттең, бөекләүгә лаек булмаган затларны бөекләдең, хөрмәткә лаек булмаган кеше һәм җен арасыннан шайтаннарны хөрмәт иттең? Синең Аллаһ каршында нинди гозерең булыр?

Кадерле дин кардәшләрем, ачыктан ачык хакыйкатьне белик: Кем Аллаһка гыйбадәт кылмаса, икенче нәрсәләргә гыйбадәт кылыр. Кем Аллаһны сөймәсә, икенче затларны сөяр. Кем Аллаһны бөекләмәсә, икенче зыян яисә файда китерергә кодрәтле булмаучы затларны бөекләр.

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының “Тәүбә” мәчете имам-хатыйбы.**

# КАЗАНДА RUSSIA HALAL EXPO ХӘЛӘЛ КҮРГӘЗМӘСЕ УЗАЧАК

Тиздән Татарстанда Хәләл-индустрия өлкәсендә әһәмиятле вакыйга көтелә. 2017 елның 18-20 нче маенда Казанда IX Халыкара икътисади саммит «Россия — Ислам дөньясы: «KazanSummit-2017» кысаларында RUSSIA HALAL EXPO Халыкара Хәләл күргәзмә узачак . Чара Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәме белән үткәрелә.

Күргәзмәне оештыручылар булып Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, «Хәләл» стандарты Комитеты һәм Татарстан Респубикасының Инвестицион үсеш агентлыгы тора.

RUSSIA HALAL EXPO күргәзмәсе «Корстон» каршысындагы мәйданчыкта урнашачак. Күргәзмәдә үз продукциясен Россия һәм Татарстаннан гына түгел, якын һәм ерак чит илләрдән дә хәләл-продукция җитештерүчеләр тәкъдим итәчәк.

Күргәзмәнең төп максаты - үзебезнең хәләл продукция һәм хезмәтләр җитештерүчеләрнең брендларын үстерү, Россия җитештерүчеләренең экспорт потенциалын алга таба мавыктыру, илебезнең хәләл секторына яңа инвестицияләр җәлеп итү, Россия икътисадында сыйфатлы продукция өлешен арттыру.

Күргәзмәнең тематик секторларында азык-төлек, күпләп һәм ваклап сәүдә итү, халык куллану товарлары тәкъдим ителәчәк.

Оештыручылар фаразлавынча RUSSIA HALAL EXPOда барлыгы 3 000 артык кеше катнашачак дип көтелә. Кунаклар исемлегендә IX Халыкара икътисади саммитта катнашучылар, шулай ук чит ил компанияләре вәкилләре, күпләп-ваклап сату компанияләре, сәүдә челтәрләре, рестораннар һәм кунакханәләр, потенциаль дилерларлар да бар.

Әлеге чара яңа эшлекле элемтәләр урнаштыру, сату базарларын киңәйтү һәм актуаль мәгълүмат алу мөмкинлеген бирә. Шулай ук киләкле товарларны һәм хезмәтләрне җитештерүчеләрне һәм кулланучыларны бер урында җыя.

RUSSIA HALAL EXPO кысаларында компанияләрне тәкъдир итү, хәләл продукцияне татып карау, мастер-класслар һәм конкурслар планлаштырылган. Күргәзмә программасында продукцияне чит илгә экспортка җибәрү мәсьәләләре буенча министрлык һәм ведомство вәкилләре белән консультацияләр үткәрү каралган.

RUSSIA HALAL EXPO - Татарстан өчен, тулаем алганда хәләл-индустрия өчен әһәмиятле вакыйга. Битараф калмыйча, әлеге чарада барыгызны катнашырга чакырабыз.

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы «Хәләл» стандарты Комитетының матбугат үзәге.**

## Язгы уйланулар

Шайтан белән көрәш бара минем,
Көн дә килә, явыз, яныма;
Намазыма бассам, әйтә миңа:
“Нәфелләрен булса да укыма!

Фарызларын үтәү житәр сина,
Әнә, кеше укымый ансын да;
Укы тизрәк, әйдә, тормыш көтә.
Күпме эшең тезелгән каршыңа.

Намаз эчендә вакыт югалтма.
Планнарын кор тирән уеңда.
Хәтерлисеңме син бу кешене,
Әйтер сүзең калган анарга”.

Шулай уза көннәр, ай да, ел да,
Кайчан ныгырсың иман юлында?
Намазларың кабулмы сон синен,
Яки өстеңнән төшерүме уеңда?

Шайтан тырыш, анын эше бара.
Тик синеке тәгәридер артка;
Уян бүген, дошман бит ул сина,
Анын сүзен кертмә тормышка.

* * *

АЛЛАһтан башка иләһ юктыр!
Бу бөек сүз чорнап алды
минем йөрәкне;
Тоткынлыктан азат булган коштай.
Күнелкәем хәзер сулый ирекне.

Бар жиһанга сибелә кебек балкып
Күкрәгемнән чыккан якты
иман нуры;
Сүрелмәсен, артсын иде бары,
Ул сүрелсә, туктар кебек тормыш юлы.

Иман белән яшим кеби мин җәннәттә-
Һәрбер аять, хәдис мине яшәртә;
Раббымны зикер кылсам әгәр,
Тормышымнан мәшәкатьләр китә.

Йә Раббым! Туры юлдан аерма,
Йөрәгемә керде мәхәббәтем Сина.
Кичер мине, рәхмәтеңнән ташлама:
Ин кирәге - Синен ризалыгын миңа.

Көннәр, атналар, айлар үтә. Ел артыннан ел уза. Үткән вакыт бер мизгелдәй тагын бергә жыелып хәтирәләр капчыгына кереп ята. Вакыт кайвакыт минем фикеремнән, уй - хыялларымнан тизрәк бара. Өлгереп булмый кайчак артыннан. Әле күпме эшләнмәгән эшләр, күпме укылмаган китап, алынмаган гыйлем, кылынмаган нәфел гыйбадәтләр... Бер туктап уйлап карыйсын. Мин ни эшләдем сон ахыйрәт өчен? АЛЛАһ ризалыгын өмет итеп нинди гамәл кылдым? Хәтирәләр капчыгын актарам. Кызганыч, күп өлеше файдасыз чүп белән тулган. Салыйм әле анда күбрәк изгелек дип ашкынсам, вакытым... Вакытым инде бик аз калган.

**Илназ хәзрәт Яхин,**
**Чаллының “Ихлас” мәчете имам-хатыйбы.**

*Редакция почтасыннан*

## Рәмзия - үрнәк дигәнне аңлата

“Рәмзия” исеме гарәпчәдән “Үрнәк” дигәнне аңлата. Аның яшәү рәвеше, эшчәнлеге, кылган гамәлләре бу исемнең җисеменә туры килүен тулысынча раслый.

Аның җитезлегенә, киң күңелле, мәгълүматлы булуына шаккатарлык. Күңел байлыгы, иманлы, сабыр булуы, тыйнаклыгы сокланырлык. “Шәһәрнең мактаулы гражданины”, “Сәламәтлек саклау отличнигы”, югары категорияле медицина хезмәткәре, бик күп газеталарның штаттан тыш хәбәрчесе, сынауларда сынатмаган, һәрвакыт күңел көрлеген саклаган тынгы белмәс каләмдәшем, хезмәт ветераны Рәмзия Шәймөхәмматова белән горурланырлык!

Рәмзия апага бер яшь тулганчы ук әтисе авырып вафат була, әниләре Нәсимә апа ике кызын ялгызы гына үстерә. Туганы — Тирсәнең данлыклы фельдшеры Бибиlә апа Әхмәтшина гел “5”ле билгеләренә тәмамлаган Рәмзияне медучилищега илтә. Беренче көннән үк аңа төркемнәрендә староста вазифасын йөкләләр.

Хезмәт юлын Варклед-Бодья медпункты мөдире булып башлый яшь белгеч. Ә хезмәт елларының соңгы 34 елы Әгерҗе район хастаханәсе белән бәйле. Райондагы һәр медицина оешмасының еллык исәп-хисабын кабул итеп, 33 ел рәттән Казанга Сәламәтлек саклау министрлыгына отчет тапшыру кебек җаваплы эшне башкара.

1974 елда, тормыш иптәше Эрнест 27 яшендә каты авырудан вафат булгач, бөтен көчен улы Илдуска һәм яраткан хезмәтенә багышлый.

Төп эшеннән тыш әллә никадәр җәмәгать эшләрен дә башкара Рәмзия апа. Медицина хезмәткәрләре профсоюзы район комитетында хезмәтне саклау комиссиясен җитәкли. Кызыл Хач һәм Ярым Ай җәмгыятенең район оешмасы рәисе булганда, 1975 ел нәтиҗәләре буенча республикада районнар арасында икенче урынны яулыйлар. Дүрт чакырылыш рәттән Әгерҗе шәһәр Советына депутат булып сайлана Рәмзия апа. Сәламәтлек саклау комиссиясе рәисе Роза Фәррахова белән шәһәр оешмаларында эшләүчеләрнең авыруларын кисәтү, мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында медицина хезмәте күрсәтүнең торышын тикшерү буенча күп эш башкаралар. Соңгы ике чакырылышта, комиссияне Рәмзия апа үзе җитәкләгән вакытта, актив депутат эшчәнлеге өчен ТАССР Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

12 ел медицина өлкәсендә эшләгәч тә, “Сәламәтлек саклау отличнигы”исеме бирелүе, урта медицина хезмәткәрләреннән иң беренче булып югары категориягә ия булуы Рәмзия апаның эшне бар күңелен биреп, җиренә җиткереп башкаруы өчен лаеклы бәя, әлбәттә.

Хәзер дә, 70 яше тулса да, аның активлыгы кимеми. Мәдрәсәдә белем алды Рәмзия апа. Алган белемен халыкка тарата, дини мәҗлесләрдә үтемле вәгазьләр сөйли, Коръән укый. Биш вакыт намазын калдырмый. Кадерлеләрен соңгы юлга озатканда да күпләр, булышуын үтенеп, аңа килә.

Язмалары бик күп газеталарда басыла. “Ватаным Татарстан”, “Татарстан яшьләре” оештырган бәйгеләрдә катнашып, призлар да алды. “Ислам нуры”нда, “Яңарыш” та, район газеталарында дин, әдәп-әхлак, күркәм кешеләр турында язмалары еш басыла. “Шәһәрнең мактаулы гражданины” булларак аны шәһәрдә уздырылган чараларга һәрдаим чакырып торалар. Хастаханәдә дә көтеп алынган кунак ул. Рәмзия апа әдәбият, сәнгать яңалыклары белән даими танышып бара. Милли баш киемнәре тегә, сәйлән белән калфакларны да бик матур чигә. Аларны күпсанлы туганнарына, дусларына, хезмәттәшләренә, танышларына бүләк итә.

Ә андый якын кешеләре бик күп аның. Элекке хезмәттәшләре белән тыгыз элемтәдә тора ул. Күпсанлы туганнары, дуслары белән аралашып яши, һәркемгә кирәк булуы белән горурлана. Ә улы Илдус, килене Энҗе, оныклары Эмил һәм Адил, тормышка гашыйк булып, матур яшәүче әниләре һәм әбиләре белән чиксез горурланалар.

**Асия КОРБАНГАЛИЕВА,**
**Әгерҗе шәһәре.**

# Намаз вакытлары

| Милади Май | Көн исеме | Шәгъбан, Рамазан | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Иртәнге намаз: Таң беленә Чаллы | Иртәнге намаз: Таң беленә Казан | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла Уфа | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла Чаллы | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла Казан | Кояш чыга Уфа | Кояш чыга Чаллы | Кояш чыга Казан | Зәвәл Уфа | Зәвәл Чаллы | Зәвәл Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дш | 5 | 02.38 | 00.34 | 00.46 | 04.07 | 02.18 | 02.31 | 05.37 | 03.48 | 04.01 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 2 | Сш | 6 | 02.32 | 00.26 | 00.38 | 04.05 | 02.16 | 02.29 | 05.35 | 03.46 | 03.59 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 3 | Чш | 7 | 02.25 | 00.17 | 00.29 | 04.03 | 02.14 | 02.27 | 05.33 | 03.44 | 03.57 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 4 | Пҗ | 8 | 02.19 | 00.06 | 00.18 | 04.01 | 02.11 | 02.24 | 05.31 | 03.41 | 03.54 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 5 | Җм | 9 | 02.12 | 23.52 | 00.02 | 03.59 | 02.09 | 02.22 | 05.29 | 03.39 | 03.52 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 6 | Шм | 10 | 02.03 | 01.37 | 01.50 | 03.56 | 02.07 | 02.20 | 05.26 | 03.37 | 03.50 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 7 | Як | 11 | 01.54 | 01.35 | 01.48 | 03.54 | 02.05 | 02.18 | 05.24 | 03.35 | 03.48 | 13.12 | 11.26 | 11.40 |
| 8 | Дш | 12 | 01.42 | 01.33 | 01.46 | 03.52 | 02.03 | 02.16 | 05.22 | 03.33 | 03.46 | 13.12 | 11.26 | 11.40 |
| 9 | Сш | 13 | 01.19 | 01.31 | 01.44 | 03.50 | 02.01 | 02.14 | 05.20 | 03.31 | 03.44 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 10 | Чш | 14 | 03.19 | 01.29 | 01.42 | 03.49 | 01.59 | 02.12 | 05.19 | 03.29 | 03.42 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 11 | Пҗ | 15 | 03.17 | 01.27 | 01.40 | 03.47 | 01.57 | 02.10 | 05.17 | 03.27 | 03.40 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 12 | Җм | 16 | 03.15 | 01.25 | 01.38 | 03.45 | 01.55 | 02.08 | 05.15 | 03.25 | 03.38 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 13 | Шм | 17 | 03.13 | 01.23 | 01.36 | 03.43 | 01.53 | 02.06 | 05.13 | 03.23 | 03.36 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 14 | Як | 18 | 03.11 | 01.21 | 01.34 | 03.41 | 01.51 | 02.04 | 05.11 | 03.21 | 03.34 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 15 | Дш | 19 | 03.09 | 01.19 | 01.32 | 03.39 | 01.49 | 02.02 | 05.09 | 03.19 | 03.32 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 16 | Сш | 20 | 03.08 | 01.17 | 01.30 | 03.38 | 01.47 | 02.00 | 05.08 | 03.17 | 03.30 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 17 | Чш | 21 | 03.06 | 01.16 | 01.29 | 03.36 | 01.46 | 01.59 | 05.06 | 03.16 | 03.29 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 18 | Пҗ | 22 | 03.04 | 01.14 | 01.27 | 03.34 | 01.44 | 01.57 | 05.04 | 03.14 | 03.27 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 19 | Җм | 23 | 03.03 | 01.12 | 01.25 | 03.33 | 01.42 | 01.55 | 05.03 | 03.12 | 03.25 | 13.12 | 11.26 | 11.39 |
| 20 | Шм | 24 | 03.01 | 01.11 | 01.23 | 03.31 | 01.41 | 01.53 | 05.01 | 03.11 | 03.23 | 13.12 | 11.26 | 11.40 |
| 21 | Як | 25 | 02.59 | 01.09 | 01.22 | 03.29 | 01.39 | 01.52 | 04.59 | 03.09 | 03.22 | 13.12 | 11.26 | 11.40 |
| 22 | Дш | 26 | 02.58 | 01.07 | 01.20 | 03.28 | 01.37 | 01.50 | 04.58 | 03.07 | 03.20 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 23 | Сш | 27 | 02.57 | 01.06 | 01.19 | 03.27 | 01.36 | 01.49 | 04.57 | 03.06 | 03.19 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 24 | Чш | 28 | 02.55 | 01.04 | 01.17 | 03.25 | 01.34 | 01.47 | 04.55 | 03.04 | 03.17 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 25 | Пҗ | 29 | 02.54 | 01.03 | 01.16 | 03.24 | 01.33 | 01.46 | 04.54 | 03.03 | 03.16 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 26 | Җм | 30 | 02.52 | 01.01 | 01.14 | 03.22 | 01.31 | 01.44 | 04.52 | 03.01 | 03.14 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 27 | Шм | 1 | 02.51 | 01.00 | 01.13 | 03.21 | 01.30 | 01.43 | 04.51 | 03.00 | 03.13 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 28 | Як | 2 | 02.50 | 00.59 | 01.12 | 03.20 | 01.29 | 01.42 | 04.50 | 02.59 | 03.12 | 13.12 | 11.27 | 11.40 |
| 29 | Дш | 3 | 02.49 | 00.58 | 01.10 | 03.19 | 01.28 | 01.40 | 04.49 | 02.58 | 03.10 | 13.13 | 11.27 | 11.40 |
| 30 | Сш | 4 | 02.48 | 00.56 | 01.09 | 03.18 | 01.26 | 01.39 | 04.48 | 02.56 | 03.09 | 13.13 | 11.27 | 11.40 |
| 31 | Чш | 5 | 02.46 | 00.55 | 01.08 | 03.16 | 01.25 | 01.38 | 04.46 | 02.55 | 03.08 | 13.13 | 11.28 | 11.41 |

| Милади Май | Өйлә Уфа | Өйлә Чаллы | Өйлә Казан | Икенде Уфа | Икенде Чаллы | Икенде Казан | Ахшам Уфа | Ахшам Чаллы | Ахшам Казан | Ястү Уфа | Ястү Чаллы | Ястү Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.23 | 16.39 | 16.52 | 20.49 | 19.07 | 19.21 | 23.05 | 21.31 | 21.44 |
| 2 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.24 | 16.40 | 16.53 | 20.51 | 19.09 | 19.23 | 23.08 | 21.35 | 21.48 |
| 3 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.25 | 16.41 | 16.54 | 20.53 | 19.11 | 19.25 | 23.12 | 21.39 | 21.53 |
| 4 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.26 | 16.42 | 16.55 | 20.55 | 19.13 | 19.27 | 23.16 | 21.43 | 21.57 |
| 5 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.27 | 16.43 | 16.56 | 20.57 | 19.15 | 19.29 | 23.20 | 20.45 | 21.59 |
| 6 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.28 | 16.44 | 16.57 | 20.59 | 19.17 | 19.31 | 23.24 | 20.47 | 21.01 |
| 7 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.30 | 16.45 | 16.58 | 21.00 | 19.19 | 19.32 | 23.28 | 20.49 | 21.02 |
| 8 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.31 | 16.46 | 16.59 | 21.02 | 19.21 | 19.34 | 23.32 | 20.51 | 21.04 |
| 9 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.32 | 16.47 | 17.00 | 21.04 | 19.23 | 19.36 | 22.34 | 20.53 | 21.06 |
| 10 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.33 | 16.48 | 17.01 | 21.06 | 19.25 | 19.38 | 22.36 | 20.55 | 21.08 |
| 11 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.34 | 16.49 | 17.02 | 21.08 | 19.27 | 19.40 | 22.38 | 20.57 | 21.10 |
| 12 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.35 | 16.50 | 17.03 | 21.10 | 19.29 | 19.42 | 22.40 | 20.59 | 21.12 |
| 13 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.36 | 16.51 | 17.04 | 21.11 | 19.31 | 19.43 | 22.41 | 21.01 | 21.14 |
| 14 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.37 | 16.52 | 17.05 | 21.13 | 19.33 | 19.45 | 22.43 | 21.03 | 21.16 |
| 15 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.38 | 16.53 | 17.06 | 21.15 | 19.34 | 19.47 | 22.45 | 21.04 | 21.18 |
| 16 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.39 | 16.54 | 17.07 | 21.17 | 19.36 | 19.49 | 22.47 | 21.06 | 21.20 |
| 17 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.40 | 16.55 | 17.08 | 21.18 | 19.38 | 19.50 | 22.48 | 21.08 | 21.21 |
| 18 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.41 | 16.56 | 17.09 | 21.20 | 19.40 | 19.52 | 22.50 | 21.10 | 21.23 |
| 19 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.42 | 16.57 | 17.10 | 21.22 | 19.42 | 19.53 | 22.52 | 21.12 | 21.25 |
| 20 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.43 | 16.58 | 17.11 | 21.24 | 19.43 | 19.55 | 22.54 | 21.13 | 21.27 |
| 21 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.44 | 16.59 | 17.12 | 21.25 | 19.45 | 19.56 | 22.55 | 21.15 | 21.28 |
| 22 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.45 | 17.00 | 17.13 | 21.27 | 19.47 | 19.58 | 22.57 | 21.17 | 21.30 |
| 23 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.46 | 17.01 | 17.14 | 21.28 | 19.49 | 20.00 | 22.58 | 21.19 | 21.32 |
| 24 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.47 | 17.02 | 17.15 | 21.30 | 19.50 | 20.02 | 23.00 | 21.20 | 21.34 |
| 25 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.48 | 17.03 | 17.16 | 21.32 | 19.52 | 20.04 | 23.02 | 21.22 | 21.35 |
| 26 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.49 | 17.04 | 17.17 | 21.35 | 19.53 | 20.05 | 23.03 | 21.23 | 21.37 |
| 27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.50 | 17.05 | 17.18 | 21.36 | 19.55 | 20.07 | 23.05 | 21.25 | 21.38 |
| 28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.51 | 17.06 | 17.19 | 21.37 | 19.56 | 20.08 | 23.06 | 21.26 | 21.40 |
| 29 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.52 | 17.07 | 17.20 | 21.39 | 19.58 | 20.10 | 23.07 | 21.28 | 21.41 |
| 30 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.53 | 17.08 | 17.21 | 21.40 | 19.59 | 20.11 | 23.09 | 21.29 | 21.43 |
| 31 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18.52 | 17.09 | 17.22 | 21.41 | 20.01 | 20.13 | 23.10 | 21.31 | 21.44 |

## Ятим балалар мәчеттә кунакта



Сидоровка бистәсе «Ихлас» мәчете Чаллы Мөхтәсибәте каршындагы «Хәзинә» клубы белән берлектә Алабуга шәһәрендә урнашкан ятим балалар йортында тәрбияләнүчеләр белән очрашу үткәрде. Балалар иртән сәг 9:00 да «Ихлас» мәчетенең бусагасыннан атлап керделәр. Иң беренче имам-хатыйб Илназ хәзрәт Яхин балаларны каршы алып, аларны Ислам дине белән таныштырды. Аннан соң балалар чапан, чалма киеп минбәргә басып карадылар. "Хәзинә" клубы җитәкчесе Ләйсән ханым балаларга сәләмләшү уены уйнатты һәм мәчет белән таныштырды. Шуннан соң балалар аскы катка төшеп чәй эчтеләр. Аннары күрешүнең икенче өлеше башланды. Балаларны Резеда ханым «беомиметика» фәне белән таныштырды. Аннан соң Ләйсән ханым белән балалар борчактан конструкцияләр ясадылар. Балалар борчак һәм төш чистарткыч таяклардан төрле биналар мәчетләр төзеп аларны үзләренә истәлеккә алдылар. Соңыннан өске катта бүләкләр кабул итеп бергәләшеп фотога төштеләр һәм зур рәхмәтләрен әйтеп кайтыр юлга юнәлделәр.

Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТТАР

Баш мөхәррире
Хәлил ШӘРИФ

Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45

* * *

Оештыручылары:
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.

Электрон хатлар өчен:
e-mail: islamnury@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавaплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

Тиражы 1100.

Индексы 54149

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
423802, Яр Чаллы,
Үзәк урамы, 72

Басарга кул куелды:
график буенча
14 апрель 16 сәг.
фактта 14 апрель 16 сәг.

Бәясе ирекле

Ислам Нуры